КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 сентябрь г.Казань № 813

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кайбер республика башкарма хакимият органнарының (Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре карамагындагы) вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру турында» 2021 ел, 5 май, 311 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кайбер республика башкарма хакимият органнарының (Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре карамагындагы) вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыру турында» 2021 ел, 5 май, 311 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 23 октябрь, 997 нче; 2022 ел, 26 май, 488 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1197 нче; 2023 ел, 20 февраль, 163 нче; 2023 ел, 14 июль, 834 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче һәм бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2024 елның 4 сентябреннән – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы «Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенә карата.»;

әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 4 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин